**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1341 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге хакында»гы карарына үзгәреш кертү турында**

2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге хакында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 1 июнендәге 2891 номерлы, 2011 елның 8 июнендәге 3071 номерлы, 2011 елның 7 декабрендәге 7861 номерлы, 2012 елның 3 июлендәге 4416 номерлы, 2013 елның 26 февралендәге 2072 номерлы, 2013 елның 6 июнендәге 5493 номерлы, 2013 елның 21 августындагы 7583 номерлы, 2013 елның 27 декабрендәге 11983 номерлы, 2014 елның 17 июлендәге 4011 номерлы, 2015 елның 10 февралендәге 632 номерлы, 2015 елның 31 мартындагы 1623 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге 2502 номерлы, 2016 елның 22 гыйнварындагы 146 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 2994 номерлы, 2016 елның 6 сентябрендәге 3731 номерлы, 2017 елның 4 декабрендәге 4962 номерлы, 2017 елның 18 декабрендәге 5258 номерлы, 2018 елның 16 февралендәге 656 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге 1397 номерлы, 2018 елның 30 маендагы 2964 номерлы, 2019 елның 12 февралендәге 521 номерлы, 2019 елның 8 июлендәге 2401 номерлы, 2019 елның 21 августындагы 2957 номерлы, 2019 елның 9 октябрендәге 3642 номерлы, 2019 елның 18 октябрендәге 3759 номерлы, 2020 елның 5 февралендәге 294 номерлы, 2020 елның 13 маендагы 1363 номерлы, 2020 елның

21 августындагы 2291 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 3888 номерлы, 2021 елның 2 апрелендәге 798 номерлы, 2021 елның 14 маендагы 1188 номерлы, 2022 елның 14 гыйнварындагы 90 номерлы, 2022 елның 25 июлендәге 2346 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 1084 номерлы, 2023 елның 6 декабрендәге 3901 номерлы, 2024 елның 6 маендагы 1904 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына, IV «Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16, 5.1, 5.2, 5.6, 2.17 статьялары белән каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары» бүлеген түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«IV. Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16, 5.1, 5.2, 5.6, 2.17 статьялары белән каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары

- комитет рәисе;
- комитет рәисе урынбасары;
- автомобиль транспорты бүлеге башлыгы;
- автомобиль транспорты бүлеге баш белгече;
- метрополитен һәм җир өсте электр транспорты бүлеге башлыгы;
- метрополитен һәм җир өсте электр транспорты бүлеге баш белгече;
- юл хәрәкәтен оештыру һәм аның иминлеге бүлеге башлыгы;
- юл хәрәкәтен оештыру һәм аның иминлеге бүлеге баш белгече;
- юл хәрәкәтен оештыру һәм аның иминлеге бүлегенең әйдәүче белгече;
- массакүләм чараларны транспорт белән тәэмин итү бүлеге башлыгы».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**